**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышев урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34

e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2023елның 27 октябре 3437 номер

# КАРАР

**Татарстан Республикасы,Лаеш муниципаль районы, Столбище авыл җирлеге, Столбище авылы, Совет урамы адрес буенча урнашкан кадастр номеры 16:24:150113:425 булган җир кишәрлеге территориясен ызанлау проектын әзерләү турында**

Территорияләрнең тотрыклы үсешен тәэмин итү, шул исәптән планлаштыру структурасы элементларын бүлеп бирү, җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү, капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41, 43, 45 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы,Лаеш муниципаль районы, Столбище авыл җирлеге, Столбище авылы, Совет урамы адрес буенча урнашкан кадастр номеры 16:24:150113:425 булган җир кишәрлеге территориясен ызанлау проектын әзерләүгә керешергә.

2. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43 статьясы нигезендә проектның эчтәлеген билгеләргә.

3. гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) уздыруны исәпкә алып проектны әзерләү срогын 2024 елның 18 апреленә кадәр билгеләргә.

4. Әлеге карар басылып чыкканнан соң, физик һәм юридик затларга территорияне ызанлау проекты тәртибе, сроклары һәм эчтәлеге турында тәкъдимнәр җибәрергә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А.П. Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**